**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
10.01.2020

КАРАР
№ ПР-1

Актаныш авылында реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына сатулар оештыру турында

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 01 декабрендәге «Актаныш муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау турында» ПР-216 номерлы, «Актаныш муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына сатулар үткәрү тәртибе турында» 04.12.2019 №ПР-290 карарлары нигезендә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә, Актаныш авылы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукы өчен, ачык (катнашучылар составы һәм бәяләр буенча тәкъдимнәр бирү формасы буенча) аукцион оештырырга һәм үткәрергә.

2. Актаныш авылында реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына ачык аукционнар үткәрү өчен билгеләргә:

- лот №1 - (Актаныш Ленин пр. Ленин паркы - яктылык белән ике яклы пилон - 4.2 м2 реклама өслеге);
- лот №2 - (Актаныш Ленин пр. Ленин паркы - яктылык белән ике яклы пилон - 4.2 м2 реклама өслеге);
- лот №3 - (Актаныш Ленин пр. Ленин паркы - яктылык белән ике яклы пилон - 4.2 м2 реклама өслеге);
- лот №4 - (Актаныш Ленин пр. Ленин паркы - яктылык белән ике яклы пилон- 4.2 м2 реклама өслеге);
- лот №5 - (Актаныш Ленин пр. Ленин паркы - яктылык белән ике яклы пилон- 4.2 м2 реклама өслеге);

3. Актаныш авылында реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешү буенча түләүнең башлангыч (минималь) күләмен исәпләү өчен Р параметрының әһәмиятен Актаныш муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешү буенча түләүнең башлангыч (минималь) күләмен (Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 4нче кушымтасы нигезендә, 04.12.2019 №Пр-290) 1000 сумга тигез дип расларга.

4. Актаныш авылында реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына аукцион үткәрү комиссиясе составын расларга (1 нче кушымта).

5. Актаныш авылында реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына ачык аукцион үткәрү, аны уздырудан баш тарту һәм гамәлдәге законнарда каралган башка аукцион шартлары турында “Актаныш таннары” район газетасында, “Интернет” челтәрендә: Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Актаныш мәгълүмат чараларының рәсми сайтында - http://aktanysh-rt.ru адресы буенча мәгълүмат җиткерү турында хәбәрләр бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.И.Гариповка йөкләргә.

**Җитәкче** **И. И. Габдулхаев**

1 нче санлы кушымта
Раслыйм ~ПР-1 от 10.01.2020г.
Башкарма комитет Җитәкчесе
И.И.Габдулхаев

**Актаныш авылында реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына аукцион үткәрү комиссиясе составы**

1. Комиссия рәисе - Р.И.Гарипов Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары
2. Комиссия рәисе урынбасары - Т.И.Имамов инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы
3. Комиссия секретаре - С.З.Газизҗанова МУП УКС инженеры
4. Комиссия әгъзасы – Н.М.Баһаветдинова җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе
5. Комиссия әгъзасы - Д.З.Сәлимов Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты юристы